| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

01.04.2021ел. Алабуга шәһәре № 62

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 116 номерлы "Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча вәкаләтләр бирү хакында"карарына үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2010 елның 30 июлендә кабул ителгән № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 116 номерлы "Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча вәкаләтләр бирү турында" гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма турында үз исеме һәм элмә тактасында урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматлар күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата (2.1 статьяда) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукына ия булу; 2.4-2.8, 2.12, 2.13, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.17, 3.2, 3.8, 3.10 статьялары (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль ташуларга карата) административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының түбәндәге вазыйфаи затларына карата:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль контроль бүлеге башлыгы урынбасары;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль контроль бүлеге баш белгечләре;

хокук тәртибен саклау җәмәгать пунктларының баш белгечләре;

- хокук тәртибен саклау җәмәгать пунктларының әйдәүче белгечләре.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р. М. Нуриев